ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 475-64/тэ-2022

«Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга житкерелә торган җылылык китерү матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 №5-100/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың кирәкле планлаштырылган тулай табышын тәгаенләштереп, 2023 елга җылылык китерү матдәсенә озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 19.12.2018 №5-100/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2019 №5-93/тэ, 11.12.2020 №410-70/тэ-2020, 10.12.2021 №483-103/тэ-2021 карарлары керткән

үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 №5-100/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 10.12.2021 №483-103/тэ-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.12.2018 №5-100/тэ
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2022 № 475-64/тэ-2022
карары редакциясендә)

## «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга җиткерелә торган җылылык китерү матдәсенә 2019-2023 елларга тарифлар

| т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык чыганагының төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык китерү матдәсенә тарифлар | | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1.1 | «Нижнекамскнефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте | Бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 19,04 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 20,11 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 19,88 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 19,88 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 19,38 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 19,41 | - |
| | | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 19,41 | - |
| | | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 22,44 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 23,80 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге